# Нәүрүз бәйрәме:



- Бу бәйрәмне безгә борынгы бабаларыбыз биреп калдырган.Урта Идел буенда яшәгән татар халкы кышлар үтеп, табигать яңара башлагач, көннең төн белән тигезләшкән бер мәлендә “Нәүрүз” бәйрәмен билгеләп үткәннәр.









# Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз бәйрәме атна-ун көн дәвам иткән. Фарсыча "Нәү"-яңа, "рүз"-көн дигәнне аңлата. Көнчыгыш календаре буенча бу-Яңа елны каршылау бәйрәме.







**УКУЧЫ БАЛАЛАР ЙОРТТАН-ЙОРТКА КЕРЕП,**

**“НӘҮРҮЗ ӘЙТЕП” ЙӨРГӘННӘР:**

***АЧ ИШЕГЕҢ КЕРӘБЕЗ,***

***НӘҮРҮЗ ӘЙТӘ КИЛӘБЕЗ,***

***ХӘЕР-ДОГА КЫЛАБЫЗ,***

***НӘҮРҮЗ МӨБӘРӘКБАД!***





Нәүрүз бәйрәме көннәрендә олылар, әби-бабайлар, өйдә матур киемнәрен киеп, махсус нәүрүз намазларын укыганнар. Гаиләгә, илгә, дәүләт башлыкларына исәнлек, тынычлык, бәхет, зур уңышлар теләп, озак-озак итеп дога кылганнар, хәерле Яңа ел килүен сораганнар. Нәүрүз бәйрәмнәре мөселман халкын киләчәккә якты өмет белән карарга өйрәткән, аларга яңа көч-дәрман, дәрт биргән, аларны тормышны яратырга өйрәткән.







“Нәүрүз”иң шатлыклы яз бәйрәме-өмет бәйрәме билгеләп үтелгән.Таң ату белән учак кабызганнар.Шул чакта итле аш яки ботка пешереп кешеләр бер-берсен сыйлаганнар.Учак әйләнәсендә балачагалар, кызлар, егетләр әйләнгәннәр.Менә шушы шәрык бәйрәме безнең көннәрдә халык йоласы буларак яңартыла. Бу көнне халкыбыз уйный, ярыша, күңел ача.








Нәүрүз җиткәч, авылның иң чибәр, бар яктан уңган-булган кызын сайлап **“Нәүрүз-бикә”** дип игълан иткәннәр.







# НӘҮРҮЗ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

